



podpiska.pochta.ru

# ЧУ! ИШЕТТЕГЕЗМЕ?

Җиһаннан чыжылдап, зур тизлек белән нидер күккә ашты. Утлы шар булып өскә күтәрелде дә, безнең күңелләрне яктыртырга теләп җиргә төште.... Соңгы тапкыр мондый күренеш белән кешелек нәкъ 100 ел элек очрашкан иде. Һәм ни гаҗәп, шушы вакыйгадан соң безнең яшәеш бары яхшы якка гына үзгәрде! Дөнья тагын да ямьлерәк, кешеләр бер-берсенә карата ихтирамлырак, елмаюлар тагын да ихласрак булып күренде.

Мәңгелек уактан утлы шарның аерылып чыгуы да яхшы хәбәргә юрый. Димәк, бу ләззәт әле озак еллар дәвам итәчәк, чөнки безнең «Ялкын»ыбыз яңа тарих язарга алынды! Киләчәктә аннан ниләр өмет итәргә? Быел җәйдә узган «Ялкын фест» чарасында «Ялкын бабай» вазифаларын ышанып тапшырырлык, үзенә лаеклы алмаш тапты. Ак өметләр баглап, алдына зур максатлар куеп, җиңелчә дулкынлану белән тарихны – «Ялкынчык» башларга тели. Әйе, ул әле безгә бик таныш түгел. Аның нинди икәнлеге, нәрсәләр белән кызыксынуы, кайсы ел фасылын аеруча яратуы, чын дуслыкка ышануы – барысы да әле зур сорау астында. Әмма куркырга кирәкми! Һәр олы вакыйганың үз кечкенә башлангычы була. Һич югы бу героебыз да безне һәрдаим бары тик матур вакыйгалар, сөенечле хәбәрләр, мавыктыргыч ачышлар белән каршылар.

Бәхет-шатлыкларың
белән кил, **«Ялкынчык»**!
Төпле аягың белән,
Ялкынның Яңа Гасыры!


автор: Азалия Сабитова

## СИН ЯЛКЫНЧЫКНЫ НИЧЕК КҮРӘСЕҢ?

podpiska.pochta.ru

# ИННОПОЛИС

## буенча сәяхәт итәбезме?



**ҖИР ЙӨЗЕНДӘ ШӘҺӘРЛӘР БИК КҮП TӨРЛЕ. КАЙСЫДЫР ИКЪТИСАД, МӘДӘНИЯТ ЯГЫННАН ЗУР ҮСЕШ АЛГАН БУЛСА, ӘЛЕГЕ ЯЗМАДА БЕЗ IT-ТЕХНОЛОГИЯЛӘР ЯГЫННАН ТАНЫЛГАН ИННОПОЛИС ШӘҺӘРЕ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШЕРБЕЗ. АЛАЙ ГЫНА ДА ТҮГЕЛ, АНЫҢ КЫЗЫКЛЫ УРЫННАРЫ БЕЛӘН ЯКЫННАНРАК ТАНЫШЫРБЫЗ.**

Көзнең бер көнендә «Ялкын» журналы редакциясе белән киләчәк шәһәренә сәяхәт кылдык. Күптәнге хыялым чынга ашты! Мин Иннополис буенча йөрдем һәм яңарышлар белән күзгә-күз очраштым.




АЛСУ КАСЫЙМОВА



ЛАЛӘ КӘРИМОВА


1

Территориягә аяк басуга ук, без пилотсыз такси күрдек. Шәһәрнең мәйданы артык зур булмаганлыктан, сез тиешле җиргә бик тиз барып җитә аласыз. Шуңысы шәп – пилотсыз таксида бушлай йөрергә була. Тик бу бәхет һәркемгә дә тәтеми. Туристлар күп булгач, ул һәрвакыт хәрәкәттә. Һәм аны тотып калу – ай-хай кыен!

2

7-11 сыйныф укучылары Иннополис лицеенда белем ала. Әлеге бина үзенең креатив булуы, заманчалыгы белән бүтәннәрдән аерылып тора. Уку, яшәү, ашау – бушка. Биредә бассейн, чүлмәк ясау остаханәсе (гончарная), спортзаллар һәм башка бик кызыклы урыннар бар. Миңа калса, иң заманча лицей нәкъ менә Иннополиста урнашкан!

3

Иннополиста А. С. Попов һәм Н. И. Лобачевский исемендәге ике технопарк бар. Без исә беренчесенә сәяхәт кылдык. Технопаркта төрле компанияләрнең офислары урнашкан. Гомумән, биредә бик акыллы абый-апалар эшли. Миңа интерьеры бик ошады. Аны ясауда өч төрле табигый чимал кулланганнар: таш, агач һәм үлән. Айтишникларга махсус ял итү өчен эшләнгән урын да бар. Анда үзеңне пыяладан ясалган түгәрәк эчендә итеп хис итәсең. Саф һавада гениаль уйлар туа бит, килешәсезме?!

4

Биредә урнашкан университет – Иннополисның «йөрәге». Нәкъ менә ул шәһәрдә беренче төзелгән бина булып тора. Югары уку йортында бүген 1000гә якын студент белем ала. Бирегә укырга керү бик кыен. Студентлар өчен барлык мөмкинлекләр дә каралган. Алар тору җирләрен 3 йолдызлы отель белән чагыштыра. Шуңа күрә, дустым, яхшылап төпле белем ал да, Иннополиска кил!

ДУСТЫМ, СИН ДӘ БЕР ВАКЫТ ТАБЫП, КИЛӘЧӘК ШӘҺӘРЕНӘ ЭКСКУРСИЯГӘ БАРЫП КАЙТ. ҮКЕНМӘССЕҢ!

Иннополистан «Әйдә, киттек!»не моннан кара!




фото: татар информ, Владимир Васи

podpiska.pochta.ru

# ОЯЛЧАН АЛМА

# «УҢЫШЛЫ УҢЫШ»



АЛСУ
КАСЫЙМОВА

АНОНИМ, 16 яшь:

**«Сыйныфташларым киләчәктә нәрсә белән шөгыльләнәчәкләрен инде белә, ә мин кая укырга керәчәгемне дә белмим. Дус-ишләрем түгәрәкләргә йөри, үзләрен төрле өлкәләрдә сыный, аларның барысы да инде үз юлын тапкан. Минем исә бернәрсә белән дә шөгыльләнәсем килми, үз-үземне беркайчан да таба алмам кебек. Миңа нишләргә?»**

Бүгенге көндә яшүсмерләрнең социаль челтәрләргә үзләренең продуктив көннәрен, уңышларын куйганнарын барыгызның да күргәне бардыр. Кемнеңдер 16 яшьтә инде үз бизнесы, 18дә эшләп алган машинасы бар. Һәм аларның барысы да бу тормышта инде үз юлын тапкан сыман. «Уңышлы уңыш» сүзтезмәсе дә нәкъ менә алар турында. Әйдәгез, моның нәрсә аңлатканын ачыклап китик!

## НӘРСӘ УЛ «УҢЫШЛЫ УҢЫШ»?

Яшүсмерләр күзлегеннән караганда, «уңышлы уңыш» ул - куелган максатларга ирешү, дөньяда үз урыныңны табу, барлык өлкәләрдә дә «гармония»да булу. Ә хәзер үз-үзегезгә сорау биреп карагыз: җир йөзендә чынлап та барлык яктан да камил булган, һәрнәрсәгә өлгерә, һәр ай саен миллионнар эшли, «янып чыкмый» торган яшүсмерләр бармы икән? Миңа калса, юктыр. Гомумән, бу термин җәмгыять тарафыннан яшүсмерләргә басым ясый кебек. Ул аларга иртә олыгаерга, табигатьтәге процессларны тизләтергә мәҗбүр итә. Ә хәзер белгеч фикере һәм киңәше белән танышыйк!





ХӘБИЛ СӘХӘБИЕВ
(ПСИХОЛОГ)

## ШӨГЫЛЬЛӘНӘСЕ КИЛМӘҮ ХИСЕ ДӘ ИГЪТИБАРГА ЛАЕК

Беренчедән, яшүсмер вакытта мондый ситуациягә проблема итеп карый алу — зур казаныш, чөнки кешеләр, гадәттә, бу ноктага олырак яшьтә килә. Кызыксынуларыңны белмәү үзең белән начар таныш булудан. Шөгыльләнәсе килмәү хисе дә игътибарга лаек. Авторга ул хис белән элемтәгә керергә, аңа төрле яклап күз салырга, өйрәнергә кирәк.

## ҺӘРДАИМ ТӨЗӘТМӘЛӘР КЕРТЕП ТОРЫРГА КИРӘК

«Аватар: легенда об Аанге» мультфильмында Аэро исемле аксакал бар. Ул үзенең бертуганының улы Зукога мондый сорау бирә: «Кем син һәм нәрсә телисең син?» – ди. Яшүсмер вакытта кеше үз-үзенә шундый сораулар бирергә тиеш һәм һәрдаим төзәтмәләр кертеп торырга кирәк. Сорауның авторы бер дә борчылмасын. Яшьләрнең 30% университетка килгәч, үзләре укыган юнәлешләрне алмаштыра. Бу — нормаль күренеш. Хәзерге заманда нинди дә булса катгый бер һөнәрне сайладың да, шуның буенча гомер буе эшләдең дигән әйбер юк.

## КЕШЕЛӘРНЕҢ УҢЫШЫН КАБУЛ ИТӘ АЛМАУ – ГАДИ КҮРЕНЕШ

«Супер» уңышлылык турында сөйләшкән вакытта, җәмгыять басымын күз алдында тотарга кирәк. «Профессионал булыр өчен, бу эш белән кечкенәдән кызыксынырга тиешсең», дигән сүзләр еш ишетелә. Ләкин бәхетле кеше булу юлы — андый гади генә түгел. Бер эш табып, гомер буе шунда эшләп, бик уңышлы булу — бәхет юлы түгел. Даими рәвештә үзең белән кызыксынып, үз халәтеңне тоеп, һөнәрләрең белән кызыксынып торсаң гына бәхеткә ирешеп була. Кешеләрнең уңышын кабул итә алмау — гади күренеш. Көнчелек тә кирәкле вакытта мотивация бирә. Ситуация өчен артык борчылу начар эмоцияләргә илтергә мөмкин. Хисләрне дөрес кичерсәң, алар сиңа кирәкле мәгълүмат бирә. Шул очракта гына кеше дөрес нәтиҗәләр ясый ала.

рәсемнәр: Freepic.com

podpiska.pochta.ru

**Иииий, Алинәм, сәлам!**

Ничек соң син? Кияүдәме, хи-хи? Шаярам. Минем санауларым буенча, сиңа хәзер инде 26 яшь.

Әлегә миңа 26 бик зур сан булып тоела, ә син күңелең белән һаман унсигездәдер. Алга планнар төзегән булам, киләчәккә дә ашыгам, тирә-яктагы якын кешеләремне дә вакыттан тизрәк атларга мәҗбүр итәм, бу миңа ярдәм иттеме? Башыңдагы идеаль тормыш картинасы чынга аштымы? Ашкандыр дип өметләнәм.

Син бит инде магистратураны да укып бетергән кеше. Вау! Җиңел бирелдеме уку? Ә эш урыны? Син кем булып эшлисең икән… Верстальщик булып танылгансыңдыр – ышанам.

Машиналар очып йөрмидер инде, анысын сорап та тормыйм. Ә менә метроның тагын бер тармагы (веткасы) инде төзелеп беткәндер, ә яшәү урыным инде мең дә бер тапкыр алышынгандыр. Питерда яшәп карау хыялыңны чынга ашырдыңмы соң?


Авылда хәлләр ничек? Күп туганнар инде исән дә түгелдер. Ә Әти белән Әни ничек? Бүлмәбез күптән энекәш карамагындадыр, ә син анда хәзер бары тик кунак.

Яратуга күмелеп яшисеңме син, 26 яшьлек Алинәм? Исемнәргә бирелмим, ул син эзләгән кеше булып чыктымы? «Беренче мәхәббәт озак яши алмый», – диләр бит, сез бу сүзләрне кире кактыгызмы?

Эх, киләчәк! Мин сиңа күпме өметләр баглыйм. Хәзергене онытып, вакыт-вакыт киләчәк турында хыяллам, ә бу миңа чыннан да кирәкме соң?

Бәхетле генә булсаң ярый инде, 5 елдан соңгы Алинәм!

10.10.24.



АЛИНӘ ЗАКИР

Исемең ____________ Дата: ____ / ____ / ____

podpiska.pochta.ru



# Һади Такташ

элемтәдә

Хат язарга

Мәкаләләр | Музыка | Сурәтләр | Подкастлар

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Зәңгәр шәл<br>Булат җыры | 3:10 | | Гөлйөзем арияce<br>Рокыя Кушловская | 3:39 | |
| Каз канаты<br>Татар хал. ав. иҗ. | 3:51 | | Хәмдия<br>Татар хал. ав. иҗ. | 3:17 | |

## Дуслар



Гадел Кутуй

Кави Нәҗми

Галиәсгар Камал

Шәриф Камал

## Берләшмәләр



«Сәйяр» труппасы

«Чаян» журналы

Татар язучылары

Казанда аңларлар

Барлык язмалар | Минем язмаларым | Архив

**Һади Такташ**

10 октябрь, 2024 ел

🥰🔥 «Ялкын» журналы минем «Алсу» поэмасына белгеч һәм мәктәп укучысы күзлегеннән анализ форматында подкаст төшергән. Бик кызык килеп чыккан, миңа ошады! QR-кодын калдырам.

❤ 1164 💬 391 ↪ 82

**Һади Такташ**


1 ноябрь, 2024 ел

😇 Иптәшләр, мин «Киләчәккә хатлар» дигән поэмамны тәмамладым. Сез дә укып китсәгез иде. Фикерләрегезне көтеп калам!

КИЛӘЧӘККӘ ХАТЛАР
Бу хат киләчәкнең билгесез бер
Кешесенә атап язылган.
Исеме безнең чорга мәгълүм түгел… тагын күрсәтергә

❤ 2347 💬 990 ↪ 96

podpiska.pochta.ru




Комикс Газетдинова Зәринә (Актаныш районы Такталачык тӘп гомуми белем бирӘмәктәбе укучысы) хикәясенә нигезләнеп ясалды.




Алсу Вәлиуллина иллюстрацияләре.

podpiska.pochta.ru